DOI: 10.26907/2311-2042-2023-20-1-175-181

# REVIEW OF ILSEYAR ZAKIROVA'S BOOK "AWAL BASHLAP NI BETTE" ("THE BEGINNING OF TIME") (KAZAN, 2017. 152 P.)

**Saviya Gimaltinovna Samitova,**
Kazan National Research Technological University,
68 K. Marx Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
savilas@yandex.ru.

The article reviews the structure of Ilseyar Zakirova's book "Awal bashlap ni bette" ("The Beginning of Time") (2017) and its place in the spiritual and cultural life of the Tatar people. The book shows the connection of myths that arose in the most ancient periods of mankind and individual phenomena of oral folk art with philosophical, religious teachings and aesthetic systems. The review evaluates the author's philosophical and aesthetic analysis of the Turks and Tatars' myths, legends and ancient beliefs, their connection with the world outlook and their reflection of the first world perceptions. The article describes such genres of folklore as dedication and ovation as a novelty of the book. It is for the first time that examples from folklore, collected by the author during the expedition to different regions where the Tatars live, have been introduced into the scientific circulation.

**Key words**: humanity, spiritual values, world image, mythology, myth, legend, folklore, genre

Everyone knows that in the era of globalization, attention to spiritual values has decreased, generation gap has deepened, traditions and customs are being forgotten, all these may lead to negative consequences. The main function of these values is to maintain harmony in the world, to provide humanity with prosperity and stability. In our spiritual life, we have transferred folk creativity, customs, traditions and beliefs to the background, thereby forgetting about their important function. The book "Awal bashlap ni bette" ("The Beginning of Time") (2017), which makes you think deeply, is all about such values.

Ilseyar Zakirova's book "Awal bashlap ni bette" ("The Beginning of Time") (Kazan, 2017. 152 p.) highlights the beliefs, spiritual canons and national traditions that arose with the emergence of mankind, the book describes the gems of folk art that must be preserved and passed down from generation to generation [1]. In the introduction, the author reflects on the role of folklore and mythology that make one understand and recreate the picture of the world of any nation: "The world image, first of all, is manifested in oral folk art – in myths, mythological stories, legends, epics, fairy tales and other genres of folklore. Information, reflecting the people's worldview, is preserved in rituals, customs and traditions. Views, as phenomena associated with the perception of the world, are believed to remain unchanged, to be timeless. The views that have arisen once are passed on from generation to generation becoming unwritten canons. This phenomenon is explained by the fact that people are unwilling to disturb stability and harmony in their thoughts and imagination" [1, pp. 3–4]. I. Zakirova explains the growing importance of continuously studying folklore along with scientific progress by the fact that the people's folklore gems include the values stored in complex sciences. The monograph contains proverbs that reflect the spiritual world of the people as well as individual episodes that represent the people's worldview: the origin of the world, parallel worlds, the emergence of the first people and the Turkic peoples, the views of the Tatars and other Turks on the soul and destiny, which are still popular, the cult of water and water creatures, calendar customs and people's views on the state and its ruler.

The book begins with the article that gives it its name "Awal bashlap ni bette (Cosmogonic mythlar ham legendalar)" ("The Beginning of Time (Cosmogonic Myths and Legends)"). In it, the author summarizes the legends and mythological beliefs of the people about the universe, heaven, celestial bodies and the origin of life, notes that the plots described in them are common or similar for all peoples living on earth. Based on Sumerian, Babylonian, Egyptian, Greek and Siberian mythologies, the book explains the initial chaos when "nothing: neither heaven, nor earth, nor night, nor day, nor life, nor death … existed". To explain the origin of all living things, the author gives parallels from the sacred books, shows their similarities and antiquity. In this study, examples from folklore, mythology, the Quran and Taurat

complement each other. Here is an excerpt from Tawrat: "And Allah said: Let there be Light … And Allah separated light from darkness. And Allah called light a day, and darkness a night…: the first day. – And Allah said: let there be firmness over water … And Allah created hardness, and separated water … And Allah called hardness heaven: the second day. This process thus continued for seven days" [1, p. 5]; it is reflected in the proverbs of the Tatar people:

What was created at the beginning? Moon and day.

What was created second? Heaven and earth [2, p. 419].

After I. Zakirova describes the processes of creating the moon and the sun, the sky and the earth within the content of the proverb, she gives an explanation, referring to the ancient works, written by V. Radlov on the Siberian Tatars, to the archaism "betu" or "bitu", which today has lost its original meaning:

| | |
|---|---|
| Awal bashlap ni betti?<br>(What was created at the beginning?)<br>Kon betti da ay betti.<br>(Day was created, and the Moon was created.)<br>Ikenchelay ni betti?<br>(What was the second created thing?)<br>Tau betti da, tash betti.<br>(Mountain was created, and stone was created.)<br>Urtasynda ni betti?<br>(What was created in the middle?)<br>Irman yushtyr ut betti.<br>(Plants were created.)<br>Any utlarga ni betti?<br>(What was created to be its host?) | Kyl koyrykly mal betti.<br>(Tailed animals were created.)<br>Ana iya bulsyn dip,<br>(To become its host,)<br>Tufraktan surat kyldyryp,<br>(From ground, from soil)<br>Adamga bash barmakcha tan betti<br>(A man was created)<br>Ber chebebcha zhan betti<br>(His soul was created) [3, p. 137] |

On the basis of the above example, the author shows that this view on the origin of the world has been completely preserved and proves that the word "bitte" means "happened".

I. Zakirova highlights the phenomenon of opposite dualism, characteristic of cosmogonic myths, and notes that initially it is seen in the struggle between light and darkness. This dualism is also reflected in the theory of Z. Freud, who explained mental processes based on folk mythology. When explaining the connections between the layers of consciousness of the Ego, Super Ego and Id, the psychologist relies on the opposite dualism, coming from mythology, and defines two types of desire. He calls the first one Eros and notes its focus on sexual desire, the desire to leave descendants, on the contrary, he considers the second one to be leading to destruction, death and calls it Thanatos.

In this work, I. Zakirova studies not only the myths related to the period of paganism, but also evaluates the changes after the adoption of Islam. To this end, the scholar turns to the Quran and the works of Arabic and Farsi scholars. She uses the work of the Farsi scholar Rashid-ad-din "Zhamig at-tavarikh" ("Jamit at-tavarikh") who lived at the turn of the $13^{th}$–$14^{th}$ centuries.

The monograph "Awal bashlap ni bette" ("The Beginning of Time") (2017) has interesting and useful notes about the genealogical legends of the Tatar people, beliefs associated with the soul, the meanings of ancient words, the mythology of fate, the adoption of Islam by the Tatars, the images of the midwife and the ruler. We do not review all the articles; here, we consider only a few entries on the topics that have not been the objects of close analysis until today.

The article "Tugan telda kylgan dogam (Tatar folklorynda bagyshlau genre)" ("A prayer in the native language (The genre of dedication in Tatar folklore)") is devoted to the genre of dedication, telling that in the $10^{th}$ century after the official adoption of Islam, the ancient values of our people received new sound, formed according to Shariah norms. The author refers to folk philosophy associated with the categories of desire, intention and thought, and notes that these categories coincide with the opinion of modern psychologists.

The texts associated with dedications and ovations, used in connection with various actions and events, are confirmed by means of the poem "Tugan tel" ("Mother Tongue") by the great poet G. Tukay. Examples are also given from records made in various areas where the Tatars live. These texts preserve the Tatar people's beliefs, originating from Islam and paganism, and the names of many personalities who are considered to be saints. I. Zakirova gives comments on the terms and names in many versions of the religious texts that she has written down herself.

The monograph provides examples of dedications, recorded from Minneakhmetova Fatima Gafievna during an expedition to the village of Tabanly Kul, the Krasnoufimsky district, the Sverdlovsk region in 2003. It presents translations of Arabic and Old Tatar words used in them; at the same time, the author indicates that there are lexemes, the meaning of which could not be established. The author believes that these words may be dialectalisms or distorted lexemes, and expresses the hope that this layer of vocabulary will be thoroughly studied in the future.

I. Zakirova devotes the article "Alkysh algan – arymas" ("He who receives an ovation will not get tired") to the genre of ovation, which today has remained unnoticed by the scholars of folklore. She notes that despite the fact that they were included in the collection of the Tatar proverbs, they were not the object of a separate scientific study. The work gives a definition of the term ovation, it is determined that this term is close in meaning to the concepts of "desire", "sacred desire" or "blessing", which are in everyday use. The Tatars attach a magical meaning to the semantic content of such words that affect a person's life in a positive way. The author writes that they are used in connection with various situations, events and customs.

In our opinion, the fact that the book refers to the image of a midwife in Tatar folklore ("Ary utyrdyn, inaleklar") indicates that the author is well acquainted with current studies, since this issue has not been the object of folklore research.

Another important aspect of the study: I. Zakirova titles each article in a simple way, referring to people themselves and using quotations from folklore, thus conveying a complex problem in a way accessible to the reader. This phenomenon does not reduce the value and scientific significance of the work, but only enhances our interest, attracting readers who know nothing about science. Each section reaches the reader, exciting interest in those who are not interested. The main meaning and value of the monograph lies, in our opinion, in the fact that after getting acquainted with the monograph, the reader retrieves knowledge from the depths of the subconscious, remembering what they have heard from their grandparents and passing it on to subsequent generations.

The article "Manke babayga salam (Tatar khalkynyn "Boz ozatu" yolasy)" ("Greetings to old man Manke (The Tatar people's custom called "Seeing off the ice")"), which required deep scientific research and led to interesting findings, is read with particular interest. The researcher presents materials about the ancient beliefs of the people, collected in Omsk, Tomsk and Novosibirsk. They are mainly used to maintain harmony in life and peacefully coexist with the reality surrounding us and invisible natural forces. The author, in order to prove her views, refers to the folklore traditions of other peoples, thereby coming to important scientific conclusions.

The author of the monograph "Awal bashlap ni bette" ("The Beginning of Time") (2017) relies on the works of V. Radlov, N. Katanov, N. Kun, S. Malov, V. Toporov, A. Khalikov, F. Khuzin, F. Urmanche, M. Bakirov, M. Piotrovsky and N. Krinichna. The outcomes of the research are presented to the reader in an academic but accessible language. The presence of works in this area proves that the research of Kh. Yarmi, N. Isanbet, F. Urmanche and M. Bakirov will be continued.

**References**

1. Zakirova, I. G. (2017). *Awal bashlap ni bette* [The Beginning of Time]. 152 p. Kazan, TILA. (In Tatar)

2. Isanbet, N. (1959). *Tatar makallare* [Tatar Proverbs]. Vol.1, 915 p. Kazan, Tat. kn. izd-vo. (In Tatar)

3. Radlov, V. V. (1872). *Obraztsy narodnoi literatury tyurkskikh plemen, zhivushchikh v Yuzhnoi Sibiri i Dzungarskoi stepi* [Samples of Folk Literature of the Turkic Tribes Living in Southern Siberia and the Dzungar Steppe]. Vol. IV. 411 p. St. Petersburg. (In Russian)

# ИЛСӨЯР ЗАКИРОВАНЫҢ «ӘҮВӘЛ БАШЛАП НИ БЕТТЕ» ДИГӘН КИТАБЫНА (КАЗАН, 2017. 152 Б.) БӘЯЛӘМӘ

**Сәвия Гималтын кызы Сәмитова,**
Казан милли тикшеренү технология университеты,
Россия, 420015, Казан ш., К. Маркс ур., 68 нче йорт,
savilas@yandex.ru.

Бәяләмәдә Илсөяр Закированың «Әүвәл башлап ни бетте» (2017) китабының төзелеше, әлеге хезмәтнең татар халкының рухи һәм мәдәни тормышындагы урыны ассызыклана. Кешелек дөньясының башлангыч чорларында барлыкка килгән мифларның, халык авыз иҗатындагы аерым күренешләрнең фәлсәфи, дини тәгълиматлар, эстетик системалар белән бәйләнеше күрсәтелә. Рецензиядә хезмәт авторының төрки-татар халыкларының дөньяны аңлау белән бәйле тәүге күзаллауларын чагылдырган мифларга, легендаларга, борынгылыктан килгән ышануларына фәлсәфи-этик анализы бәяләнә. Табигатьләре аз ачылган, яисә галимнәрнең игътибарыннан читтә калган багышлау, алкыш кебек фольклор жанрларын шәрехләү китапның фәнни яңалыгы төсендә күрсәтелә. Татарлар оешып яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган экспедиция вакытында автор тарафыннан язып алынган фольклор үрнәкләренең беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелүе һәм шәрехләнүе әйтелә.

**Төп төшенчәләр**: кешелек дөньясы, рухи кыйммәтләр, дөнья картинасы, мифологема, миф, легенда, фольклор, жанр

Барыбызга да мәгълүм: глобальләштерү чорында рухи кыйммәтләргә игътибар кимү, буыннар арасында бәйләнеш югалу, гореф-гадәтләрнең югала баруы күңелсез нәтиҗәләргә китерде. Бу кыйммәтләрнең төп функциясе дөньяда гармония саклауда, кешелекне иминлек, тотрыклылык белән тәэмин итүдә билгеләнә. Без рухи тормышыбызда халык иҗатының, гореф-гадәтләрнең, йолаларның, ышану-сынамышларның әһәмиятен арткы планга чыгарып, шул турыда онытып җибәрдек. Укып чыккач, күңелдә тирән уйланулар тудырган «Әүвәл башлап ни бетте» (2017) дигән китапта шушы кыйммәтләр турында сүз бара.

Илсөяр Закированың «Әүвәл башлап ни бетте» (Казан, 2017. 152 б.) хезмәтендә кешелек дөньясы белән бергә барлыкка килгән ышану-инанулар, әхлак кануннары, рухи кыйммәтләр, милли традицияләр яктыртыла, ул, буыннан буынга тапшырылып, сакланырга тиешле халык ядкярләрен шәрехләүгә багышлана [1]. Китапның кереш өлешендә автор фольклор һәм мифология ярдәмендә теләсә кайсы халыкның дөнья картинасын күзаллау һәм торгызып булу хакында фикер йөртә: «Дөнья картинасы, беренче чиратта, халыкның тел иҗатында – мифларда, мифологик хикәятләрдә, легендаларда, эпоста, әкиятләрдә һәм фольклорның башка жанрларында чагыла. Халыкның дөньяны күзаллавы турындагы мәгълүмат ритуалларда, йолаларда, гореф-гадәтләрдә саклана. Дөньяны күзаллау белән бәйле карашлар, күренешләр, вакыттан тыш, үзгәрми торган кыйммәтләрдән санала. Бер барлыкка килгән карашлар гасырдан гасырга күчеп килеп, язылмаган кануннар буларак кабул ителгән. Бу күренеш халыкның билгеле бер тотрыклылыкны, аңында яки хыялында гына булса да яшәп килгән гармонияне бозудан куркуы белән бәйләп аңлатыла» [1, 3-4 б.]. И.Г. Закирова фәнни прогресс белән берлектә фольклорны өйрәнүнең әһәмияте көннән-көн артуын халык җәүһәрләренең үз эченә катлаулы фәннәрдә сакланган кыйммәтләрне дә сыйдыруы белән аңлата. Монографиягә халыкның рухи дөньясын, дөньяны кузаллавын чагылдырган аерым эпизодлар: дөнья яратылу, параллель дөньялар, беренче кешеләр барлыкка килү һәм төрки халыкларның килеп чыгуы, татар һәм башка төркиләрнең җан һәм язмыш турындагы карашлары, хәзергә кадәр популярлыгын җуймаган су һәм су ияләре культы, календарь йолалар һәм халыкның дәүләт һәм хөкемдар турындагы карашлары сурәтләнгән мәкаләләр кергән.

Китап аңа исем буларак чыккан «Әүвәл башлап ни бетте (Космогоник мифлар һәм легендалар)» мәкаләсе белән ачыла. Анда автор халкыбызның галәм, күк һәм күк җисемнәре, җир һәм тереклек барлыкка килү турындагы легендаларын һәм мифологик ышануларын барлый, аларда тасвирланган сюжетларның дөньяда яшәүче бар халыклар белән уртак яки

бик охшаш булуын ассызыклый. Шумер, Вавилон, Мисыр, Грек, Себер халыклары мифологияләрен күзәтеп: «бер нәрсә дә: күк тә, җир дә, төн дә, көн дә, яшәү дә, үлем дә юк иде» дигән сурәтләү аркылы, беренчел хаосны аңлата. Тереклек яратылу турында мисалларга изге китаплардан параллельләр китерә, аларның уртак якларын һәм борынгылыгын күрсәтә. Фәнни хезмәттә фольклордан, мифологиядән, Коръән һәм Тәүраттан китерелгән үрнәкләр бер-берсен тулыландырып килә. Мәсәлән, Тәүраттан китерелгән мисал «Һәм Алла әйтте: Яктылык бар булсын… Һәм Алла яктылыкны караңгылыктан аерды. Һәм Алла яктылыкны көн дип, караңгылыкны төн дип атады…: беренче көн. – Һәм Алла әйтте: су өстендә катылык бар булсын… Һәм Алла катылыкны бар кылды, һәм суны аерды… Һәм Алла катылыкны күк дип атады: икенче көн». Бу процесс шул рәвешле җиде көн дәвам итә» [1, 5 б.] татар халык мәкальләрендә чагылыш таба:

Әүвәл башлап ни бетте? Ай бетте дә көн бетте.

Икенчеләй ни бетте? Күк бетте дә җир бетте [2, 419 б. ].

Мәкаль эчтәлегендәге ай белән кояш, күк белән җир яратылу күренешләренә күзәтү ясаганнан соң, автор бүгенге көндә беренчел мәгънәсен югалткан «бетү» яки «битү» архаизмына аңлатма биреп, И. Закирова В.В. Радловның Себер татарларыннан язып алган борынгы әсәрләренә мөрәҗәгать итә:

| | |
|---|---|
| Әүвәл башлап ни битти?<br>Көн битти дә, ай битти.<br>Икенчеләй ни битти?<br>Тау битти дә, таш битти.<br>Уртасыда ни битти?<br>Ирмән юшыр ут битти.<br>Аны утларга ни битти? | Кыл койрыклы мал битти.<br>Аңа ия булсын, дип,<br>Туфрактан сурәт кылдырып,<br>Адәмгә баш бармакча тән битти,<br>Бер чебенча җан битте [3, 137 б.] |

Автор югарыдагы үрнәккә таянып, дөнья барлыкка килү турындагы карашның тулысынча саклануы хакында искәртә һәм «битте» сүзенең «яратылу» мәгънәсенә ия булуын исбатлый.

И. Закирова космогоник мифларга хас булган капма-каршы дуализм күренешенә игътибар биреп, аның, башлыча, яктылык һәм караңгылык арасындагы көрәштә чагылуын ассызыклый. Бу дуализм психик процессларны халык мифологиясенә нигезләнеп аңлаткан З. Фрейдның теориясендә дә чагылыш таба. Аңлылыкның Эго, Супер Эго һәм Ид катламнары арасында барган бәйләнешләрне аңлатуда психолог мифологиядән килүче капма-каршылык дуализмына таяна һәм ике төр дәрт барлыгын билгели. Аның беренчесен Эрос исеме белән атап, сексуаль дәртлелеккә һәм яшәүгә, нәсел калдыруга юнәлтелгән булуын, икенчесенең исә, киресенчә, җимерүгә, үлемгә китерүен билгеләп, Танатос дип атый.

И. Закирова бу мәкаләсендә мәҗүсилек чорына караган мифларны гына өйрәнеп калмый, ә Ислам дине кабул ителгәннән соң кергән үзгәрешләрне дә бәяли. Бу максаттан галимә Коръәнгә һәм гарәп-фарсы галимнәренең хезмәтләренә мөрәҗәгать итә. XIII – XIV гасырлар чигендә яшәгән фарсы галиме Рәшид-әд-диннең «Җәмигъ әт-тәварих» хезмәтен яратып файдалана.

«Әүвәл башлап ни бетте» (2017) монографиясендә татар халкының генеологик легендаларына, җан белән бәйле ышануларына, борынгы *кот* сүзенең мәгънәләренә, язмыш мифологемасына, татар халкының ислам динен кабул итү турында, кендек әбиләре һәм хөкемдар образларына багышланган гаять эчтәлекле һәм кызыклы язмалары урын алган. Рецензиядә, мәкаләләрнең барысына да күзәтү ясауны үзмаксат итмәү сәбәпле, бүгенге көнгә кадәр тирән анализ булмаган темаларга багышланган берничә язманы гына шәрехләп китәргә булдык.

«Туган телдә кылган догам (татар фольклорында багышлау жанры)» дигән язма багышлау жанрының, X гасырда Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң, халкыбызның борынгы кыйммәтләренең яңа яңгыраш алуы, аларның шәригать кануннарына нисбәтле рәвештә формалашуы турында сөйли. Автор теләк, ният һәм уй-фикер категорияләре белән бәйле халык фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә, ул категорияләрнең бүгенге психологлар фикере белән тәңгәл килүен ассызыклый.

Төрле эш-гамәлләр һәм вакыйгалар белән бәйләнештә кулланылган багышлауларга, алкышларга мөнәсәбәтле текстларга мәшһүр шагыйрь Г. Тукайның «Туган тел» шигыреннән дәлилләр китерелә. Шулай ук татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән язып алынган үрнәкләр дә тәкъдим ителә. Бу текстларда татар халкының

ислам һәм мәҗүсилектән килгән ышанулары, изге саналган күп кенә шәхесләренең исемнәре саклануы күренә. И. Закирова күп вариантларда үзе язып алган дини эчтәлекле текстларда сакланган терминнарга, исемнәргә дә шәрех биреп бара.

Монографиядә Свердловск өлкәсенең Красноуфимский районы Табанлы Күл авылына 2003 елда оештырылган экспедиция вакытында Миңнеәхмәтова Фатыйма Гафи кызыннан язып алынган багышлауларның үрнәкләре бирелә. Аларда кулланылган гарәп һәм иске татар сүзләренә тәрҗемә китерелә, шул ук вакытта мәгънәләрен табып булмаган лексемалар барлыгы хакында языла. Боларның диалектализмнар, яки бозылган сүзләр булу ихтималын искәртеп, автор лексиканың бу катламы киләчәктә галимнәр тарафыннан өйрәнелү мөмкинлегенә ышаныч белдерә.

«Алкыш алган – арымас» мәкаләсен И. Закирова бүгенге көндә фольклористика фәнендә галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән алкыш жанрына багышлый. Аларның, татар паремияләре составына кертелүләренә карамастан, аерым фәнни тикшерену объекты булмавын искәртеп үтә. Алкыш терминына аңлатма бирелә, көндәлек кулланышта булган «теләк», «изге теләк» яки «хәер-фатиха» кебек гыйбарәләрнең алкыш термины белән тәңгәл булуын ачыклаганнан соң, татар халкының мондый сүзләрнең асылына кеше тормышына уңай тәэсир итә алырлык магик мәгънә салуларын ассызыклый һәм аларның төрле шартларга һәм вакыйгаларга, йолаларга бәйле рәвештә башкарылуы хакында искәрмә бирә.

Минем карашымча, китапта татар фольклорында кендек әбиләре образларына урын бирү («Ары утырдың, инәлекләр») дә галимәнең бүгенге фән торышын яхшы белүен күрсәтә, чөнки әлеге мәсьәлә дә фольклористикада өйрәнү объекты буларак тикшерелмәгән дияргә була.

Шунысы мөһим һәм кызыклы: И. Закирова һәр мәкаләсен гади формада, халыкның үзенә мөрәҗәгать итеп һәм фольклордан алынган цитаталар белән атый, шул рәвешле катлаулы мәсьәләләрне аңлаешлы итеп укучыга җиткерә. Бу күренеш хезмәтнең кыйммәтен һәм фәнни асылын киметми, бәлки аңа игътибарны арттыра гына: чөнки бу атамаларда нindидер кысыксындыру, тарту көче барлыкка килә һәм ул фәннән шактый ерак торган милләттәшләребезне дә җәлеп итә. Һәр аерым бүлекчә укучыны кузгатып җибәрә, гамьсезләргә гамь кертә. Монография белән танышу нәтиҗәсендә укучының, хәтер төпкелләреннән үзе белгәннәрне тартып чыгарып, әби-бабаларыннан ишеткәннәрен искә төшереп, аларны киләчәк буыннарга тапшыруында, безнең карашыбызча, китапның төп әһәмияте һәм кыйммәте билгеләнә.

Тирән фәнни эзләнүләрне таләп иткән, кызыклы ачышларга китергән «Мәңке бабайга сәлам (Татар халкының «Боз озату» йоласы)» мәкаләсе аеруча зур кызыксыну белән укыла. Галимә, Омск, Томск, Новосибирск якларында туплаган материалларына нигезләнеп, халкыбызның борынгыдан килгән ышануларын барлый. Аларның, нигездә, кешене чорнап алган әйләнә-тирә, тереклек һәм дә күренмәс табигый көчләр белән янәшә тыныч гомер итү максаты, тормыштагы гармонияне саклау нияте белән башкарылуы турында фикер әйтә. Карашын исбатлау өчен, башка халыкларның фольклор традицияләренә дә мөрәҗәгать итеп, кыйммәтле фәнни нәтиҗәләргә килә.

«Әүвәл башлап ни бетте» (2017) монографиясенең авторы В.В. Радлов, Н.Ф. Катанов, Н.А. Кун, С.Е. Малов, В.Н. Топоров, А.Х. Халиков, Ф.Ш. Хуҗин, Ф.И. Урманче, М.Х Бакиров, М.Б. Пиотровский, Н.А. Кринична хезмәтләренә таяна, өйрәнү барышында ачылган фикерләрне академик, шул ук вакытта аңлаешлы телдә укучыларга җиткерә. Бу шәкелдәге хезмәтләрнең басылып торуы Х. Ярми, Н. Исәнбәт, Ф. Урманче һәм М. Бакировларның эстафетасын дәвам итүчеләр барлыгын, һичшиксез, исбатлый.

**Әдәбият**

1. Закирова И.Г. Әүвәл башлап ни бетте. Казан: ТӘҺСИ, 2017. 152 б.
2. Исәнбәт Н. Татар мәкальләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 1959. Т.1. 915 б.
3. Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч.IV. СПб., 1872. 411 с.

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ ИЛЬСЕЯР ЗАКИРОВОЙ «ӘҮВӘЛ БАШЛАП НИ БЕТТЕ» («КАК СОЗДАЛСЯ МИР») (КАЗАНЬ, 2017. 152 С.)

**Савия Гималтыновна Самитова,**
Казанский национальный исследовательский технологический университет,
Россия, 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, д. 68,
savilas@yandex.ru.

Статья носит характер рецензии на книгу Ильсеяр Закировой «Әүвәл башлап ни бетте» («Как создался мир»), увидевшей свет в Казани в 2017 году. В рецензии отмечается, что автор рассматривает миропонимание народа как сложное явление, которое является системой, состоящей из фрагментов, актуальных по отношению к конкретным ситуациям. Эта система называется моделью мира. В книге реконструирована на основе фольклорного материала модель мира татарского народа. Это прежде всего то, что реализовано на языковом уровне: в текстах эпосов, сказок, мифов, легенд, быличек, загадок, пословиц, песен и т. д. Ритуалы, обряды, обычаи, составляющие ритуальное поведение, также хранят важную информацию о мировоззрении народа.

Впервые в научный оборот вввведены образцы фольклора, записанные автором во время экспедиций в различные регионы компактного проживания татар. Рецензент отмечает богатство и разнообразие анализируемого фольклорного материала, выверенность научного инструментария. В статье подчеркивается ценность и значение этой монографии в изучении духовной жизни татарского народа.

**Ключевые слова:** человечество, духовные ценности, образ мира, мифология, предание, фольклор, жанр